Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Советы
# КАРАРЫ

2020 елның 23 октябре 16№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 5 мартындагы «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәле яки аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 60 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварендагы «Аерым категория затларның беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка аларда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында»10 номерлы (2015. 12.10 ред.) карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 5 мартындагы «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хәле яки аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 60 нчы карарына (2019.25.10, 262№ үзгәрешләр белән) ( алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктын өстәргә:

«13.1. Кыйммәтле металлдан һәм (яисә) кыйммәтле ташлардан әзерләнгән бүләккә дәүләт вазыйфаларын биләүче затлардан, дәүләт хезмәткәрләреннән әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза килмәгән яисә күрсәтелгән затлар кыйммәтле металлардан һәм (яисә) кыйммәтле ташлардан әзерләнгән мондый бүләкне сатып алудан баш тарткан очракта, вәкаләтле структур бүлекчә (вәкаләтле орган яисә оешма) тарафыннан Россия Федерациясенең кыйммәтле металлар һәм кыйммәтле

ташларның Дәүләт фондына күчерү өчен «Россия Федерациясе Финанс министрлыгы каршындагы кыйммәтле металл һәм кыйммәтле ташлар дәүләт фондын формалаштыру, саклау, җибәрү һәм алардан файдалану буенча дәүләт учреждениесе» федераль казна учреждениесенә тапшырылырга тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район
муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин